ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2018 Казан ш. № 5-30/тэ

"Республика "Таткоммунэнерго" житештерү берләшмәсе" Акционер җәмгыяте тарафыннан Дәүләт комитетының 2016 елның 15 декабрендәге 5-59/тэ карары белән билгеләнгән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итә торган башка оешмаларга бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) озак вакытка каралган тарифларга 2019 елга төзәтмәләр кертү турында

"Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында"2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, һәм 2019 елга җылылык энергиясенә (куәтенә) озакка исәпләнгән тарифларны үзгәртү максатыннан, 2019 елга җайга салына торган оешманың планнаштырылган тиешле тулаем керемен ачыклап, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Республика «Таткоммунэнерго» Республика житештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2017 – 2019 елларга тарифлар билгеләү турында" 2016 елның 15 декабрендәге 5-59/тэ номерлы карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 1 декабрендәге 5-53/тэ номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада "Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының "2029 елга кадәр Казан шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында" 2015 елның 13 мартындагы 130 номерлы боерыгы белән" сүзләрен "Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының "2033 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында" 2018 елның 16 августындагы 658 номерлы боерыгы белән" сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитеты
карарының 1нче кушымтасы
15.12.2016 № 5-59/тэ
номерлы карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
23.11.2018 № 5-30/тэ
номерлы карары редакциясендә)

## 2017 – 2019 елларга «Республика «Таткоммунэнерго» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәүмин итә торган башка оешмаларга бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) календарь бүленешле тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="2">№ т/б</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлекнең, җайга салына торган оешманың исеме, тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Су</th><th colspan="4">Иң көчле басымлы пар</th><th rowspan="2">Коры һәм көчсезлән-дерелгән пар</th></tr>
<tr><th>1,2 алып 2,5 кг/см$^2$ кадәр</th><th>2,5 алып 7,0 кг/см$^2$ кадәр</th><th>7,0 алып 13,0 кг/см$^2$ кадәр</th><th>13,0 кг/см$^2$ күбрәк</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="8">Казан шәһәре</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="8">«Республика «Таткоммунэнерго» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте</td></tr>
<tr><td>1.1</td><td colspan="8">Тоташтыру схемасы буенча тарифлар бүлеп каралмаган очракта, кулланучылар өчен</td></tr>
<tr><td rowspan="6"></td><td rowspan="6">бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>2017 елның 1 гыйнварыннан алып 2017 елның 30 июненә кадәр</td><td>1181,73</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2017 елның 1 июленнән алып 2017 елның 31 декабренә кадәр</td><td>1231,36</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2018 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 30 июненә кадәр</td><td>1231,36</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр</td><td>1256,10</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр</td><td>1256,10</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр</td><td>1278,93</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге